Татар мәктәбендә укучы балаларга
татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
10 нчы сыйныф
2016-2017 уку елы

**Үткәрү вакыты- 120 минут**
**Максималь балл – *69***

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Басымы дөрес күрсәтелгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) кай-та-сыз-мы′;

ә) кай-та-сы′з-мы;

б) кай-та′-сыз-мы;

в) ка′й-та-сыз-мы.

2. Татар алфавитындагы хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) 38;

ә) 36;

б) 39;

в) 40.

3. Бирелгән мисалдагы омонимнарның төрен билгеләгез: ***(2 балл)***

*Яшен уйнап, күк күкрәде –*

*Беренче яшен.*

*Күк күкрәде, сискәндереп*

*Картын һәм яшен.* (М.Шабаев)

а) омофон;

ә) омограф;

б) омоформа;

в) саф омоним.

4. Кулланылган рәвешнең төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Вакытны бушка уздырган кеше ахмак.* (Мәкаль)

а) вакыт рәвеше;

ә) күләм-чама рәвеше;

б) урын рәвеше;

в) сәбәп-максат рәвеше.

5. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльгә дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Чәчәк күрсәтмәгән агачтан җимеш* ***көтмә***. (Мәкаль)

а) боерык фигыль, затланышлы, тамыр сүз, юклыкта, IIзат берлек санда;

ә) боерык фигыль, затланышлы, тамыр сүз, барлыкта, IIзат берлек санда;

б) хикәя фигыль, затланышлы, тамыр сүз, юклыкта, IIзат берлек санда;

в)шарт фигыль, затланышлы, тамыр сүз, юклыкта, IIзат берлек санда.

6. Кисәкчәләре дөрес язылган сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) иң матур, сөйли ич, кил че, кып-кызыл;

ә) кайттың мы, син генә, иң-зур, чем кара;

б) һичкайчан, әйт инде, чем-кара, матурдыр;

в) бик чибәр, кайт кына, һич кем, нәкъ үзе.

7. Модаль сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) кебек, ягъни, чөнки, янәсе;

ә) ур-ра, соң, бугай, ахры;

б) дөрес, әлбәттә, бәлки, мөгаен;

в) әллә, ихтимал, сәлам, ич.

8. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Их, менә хәзер моны малайларга күрсәтәсе иде!* (Р. Низамиев)

а) хикәя, тойгылы, җәенке, ике составлы, ким;

ә) боерык, тойгылы, җәенке, ике составлы, ким;

б) хикәя, тойгылы, җәенке, ике составлы, тулы;

в) хикәя, тойгылы, җәенке, бер составлы, тулы.

9. Җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Инде әбиемнең куллары каткан, бармаклары нечкәреп, сөякләнеп калган.* (Н.Дәүли)

а) гади җөмлә;

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;

б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;

в) күп тезмәле кушма җөмлә.

10. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Сынаган бар: сине сагынганда,*

*Әнкәй искә төшә нигәдер.* (Г.Гыйльманов)

а) тиңдәш түгел иярүле;

ә) берничә төр иярүле;

б) тиңдәш иярүле;

в) бер-бер артлы иярүле.

11. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Әти алма, лимон, кара җимеш ише нәрсәләрне еш алып кайтса да, конфет, печенье кебек тәмле-томлылар гает шикелле зур бәйрәмнәрдә генә алып кайтылганлыктан, арзанлы камыр конфет та тансык иде безгә.* (С.Әдһәмова)

а)тиңдәш иярүле;

ә) тиңдәш түгел иярүле;

б) бер-бер артлы иярүле;

в) берничә төр иярүле.

12. Җөмләдәге тыныш билгеләре дөрес куелган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Кара әле улым тыңла әле ипине алай мыскыл итеп типкәләп уйнарга ярамый бит* (А.Шамов)

а) Кара әле, улым, тыңла әле: ипине алай мыскыл итеп, типкәләп уйнарга ярамый бит.

ә) Кара әле улым, тыңла әле: ипине алай мыскыл итеп, типкәләп уйнарга ярамый бит.

б) Кара әле, улым тыңла әле: ипине алай мыскыл итеп, типкәләп уйнарга ярамый бит.

в) Кара әле, улым, тыңла әле, ипине алай мыскыл итеп, типкәләп уйнарга ярамый бит.

## II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмләләрдәге тыныш билгеләрен аңлатып языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

## III. Грамматик һәм иҗади бирем.

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне языгыз, түбәндә бирелгән грамматик һәм иҗади биремнәрне үтәгез.

БЛТР КСКНГ, БЙЛ КЧКРМЙЛР. ***(4 балл)***

1. Мәкальдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. ***(4 балл)***

2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, җөмләнең схемасын сызыгыз, билгеләмә бирегез. ***(10 балл)***

3. Өченче сүзгә фонетик анализ ясагыз. ***(4 балл)***

4. Мәкальдә кулланылган сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. ***(4 балл)***

5. Беренче сүзнең синонимын языгыз. ***(2 балл)***

6. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(7 балл)***